Федеральное государственное бюджетное образовательное учреждение высшего образования Башкирский государственный педагогический университет им. М. Акмуллы

Заключительный этап Всероссийской олимпиады школьников и студентов организаций СПО «Акмуллинская олимпиада» по «Татарскому языку»

10-11 классы, студенты СПО

1 вариант

(2025-2026 уч. год)

Бирем 1. Алынма сүзләрне татар телендәге төрки чыганаклы сүзләр белән алыштыр (5 б.)


Сәгадәт _____

Фәкыйрь_____

Куәт_____

Мөстәкыйль_____

Низаг_____

Бирем 2. Иң борынгы төрки алфавит – рун хәрефләре белән язылган  –“*сакынтым*” (сагындым) сүзе язылган. Рун хәрефләре белән НЫК, САН, ТЫН, КАТЫ сүзләрен яз (8 б.).

_____

Бирем 3. Хата кайда? (5 б.)

Иртәгә Зөһрә иптәш кызын каршы алырга бара. Ул ак күлмәктән булачак. _____

Бүген суга баткан бер баланы азат иттеләр. _____

Урамнан үткән саен өреп чыга торган Сәхи картның ала эте бүген нигәдер күренмәде. _____

Басу юлыннан биш чөгендер төягән машина үтеп бара._____

Оялуыннан Әсманың чырае кызарып китте._____

Бирем 4. Гәүдә өлеше атамасы һәм фразеологик берәмлекнең лексик мәгънәсе арасында тәңгәллек урнаштырыгыз. Шушы мәгънәгә туры килгән фразеологик берәмлек языгыз (8 балл).

Мәсәлән, Авыз – алдану (Авызы пешү)

Күз	Авыз	Колак	Теш
“аппетит, ашыйсы килү”	“ачу тоту”	“шаккатып тыңлау”	“сай уйлаучы, җавапсыз”

_____
_____
_____
_____

Бирем 5. Язылыш принцибы ягыннан тикшереп, төркемдәге артык сүзләрне билгеләгез (4 б.)
Башлангыч, эзсез, унбер, сузынкы, студент _____
Абитуриент, ди-джей, принтер, спектакль, дәрәҗә _____

Бирем 6. Һади Такташның “Мокамай” шигыреннән өзектә бер сүздә хата киткән. Бу сүзне табып, дөрес вариантын языгыз (3 б.)_____

Кем уйлаган шушы шаярулар
Синдә кәсеп булып калыр дип,
Уйнап башланган эш тормышыңны
Халыкка алып барыр дип... _____

Мокамайның үз исеме нинди? (2 б.)_____

Бирем 7. Урта диалектның тау ягы сөйләшендәге ГОМБАКТЫ “подсолнух” сүзе татар әдәби телендә ничек була? Ул нинди фонетик күренеш нәтиҗәсендә шулай үзгәргән? (3 б.)

_____

Бирем 8. Күчерелмә мәгънәдәге сүзләрнең антонимнарын билгеләгез (4 б.)

Ишәк_____
Куян_____

Бирем 9. В. Колечицкийның “Архаизм – ул пенсиядәге неологизм” дигән афоризмын ничек аңлыйсыз? (3 б.) Неологизмга 4 мисал китерегез (2 б.)._____
_____

Бирем 10. Түбәндәге сүзләрне русчага тәрҗемә итегез (3 б.)

Хосусый мәктәп_____
Магнит давылы_____
Сәүдә-сәнәгать палатасы_____
Тере акча_____
Тимер пәрдә_____

Бирем 11. Өзекне игътибар белән укып чык. Текст буенча биремнәрне үтә.

1) Гыймадовларның гаилә тормышлары да Мясниковларныкына бер дә охшамый. 2) Борһан абзый гади бер татар сәүдәгәре һәм гади татар бае

тормышы белән тора торган кеше иде. 3) Шуңа күрә аның йортындагы һәр кеше, үз теләге һәм үз тойгыларына буйсынудан бигрәк, борынгыдан эшләнеп килгән кагыйдәләргә буйсынырга һәм шулар билгеләп куйган юлдан чыкмый барырга тиеш иде. 4) Әмма Мясниковлар гаиләсендә берничә генә нәрсәне исәпкә алмаганда, һәркемнең үз теләге, үз тойгылары бик күп урында, бик күп нәрсәләрдән алда тотыла иде.

5) Шулай итеп, безнең _____ ике, бер-берсенә бөтенләй каршы тормыш агымнары уртасында үсте. 6) Рус җәмгыятенең күңелле тормышы аның яшь йөрәген үзенә тарта да, ул Мясниковлар һәм башка кайбер рус гаиләләренең күңелле вечерларында төнге сәгать өчкә кадәр танцевать итә ала иде. 7) Икенче яктан, үз гаиләләрендәге тормыш һәм кечкенәдәге тәрбия аның җанын чолгап ала да, ул, шундый кызыклы вечерлардан арып-талып кайтып урынына яткач, икешәр сәгать тоташ төрле догалыклар һәм салаватлар укынып та ята ала иде. 8) _____ тормышны ике төрлегә аера: мөселман тормышы – монысы үзләренекечә булырга тиешле; рус тормышы – монысы Мясниковларныкыча булырга кирәк дип ышана иде. 9) Менә шул ышану нәтиҗәсе – _____ бу ике тормышның икесе белән дә торса да, аларның бер-берсенә кушылып, үрелеп китүләреннән курка, икесен йөрәгенең ике почмагына яшереп, араларына калын бер пәрдә корып куя иде.

Күпнокталар урынына геройның исемен куй (2 б.)_____
Әсәрнең авторы кем? (2 б.)_____
Автор турында 5 факт яз (5 б.)**:**
_____
_____
_____
_____
_____
2)нче җөмләдәге хәбәрнең төре нинди? (2 б.)_____
9)нчы җөмләгә кайсы билгеләмә туры килә а) катнаш кушма җөмлә, б) иярченле кушма җөмлә, в) тезмә кушма җөмлә, г) гади җөмлә? (3 б.)
_____
Түбәндәге тел күренешләре булган җөмлә номерларын куярга (5 б):
1) аерымланган вакыт хәле
2) кереш сүз
3) инфинитив
4) парлы сүз
5) “урап” сүзенә синоним сүз булган җөмлә

1)	2)	3)	4)	5)

6)нчы җөмләдә ни өчен өтер куела? (2 б.)_____
3)нче җөмләдәге ТОЙГЫЛАРЫНА сүзендә ничә кушымча бар? (3 б.)_____

Бу әсәрдәге геройларның күңелендә булган хис-тойгыларны, кичерешләрне санап чык (6 б.): _____

_____

Бирем 11. *Мин үзем гомер буе җыр белән бәхетле булдым. Миңа ул бәхет бик ерактан балачактан килә. Минем алтмыш еллык гомеремне мәктәп еллары, хәрби хезмәт, институт, аспирантура, укытучылык хезмәте елллары буенча исәплисе түгел, аларны – җырлар белән исәплисе* (М. Мәһдиев).

Тексттагы ИСӘПЛИСЕ фигылен граматик мәгънәсе буенча туры килгән нинди форма белән алыштырырга мөмкин? (2 б.)_____

Фигыльнең бу формасы ничек атала? (2 б.) _____

Син бу тормышта бәхетлеме? Нәрсә ул бәхет? Шул турыда фикерләреңне яз. Иҗади эштә төрле сурәтләү чаралары булсын, тирә-юньгә, вакыйгаларга синең мөнәсәбәтең белдерелсен. Язма эшнең күләме 100 сүздән ким булмасын. Эшне чиста, төзәтүләрсез һәм танырлык итеп яз (16 б.).

_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____.

Для 10-11 классов, студентов СПО максимальное количество баллов за все задания – 100 баллов